| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от_04.03.2020_ г. Казань № ___32_____

**Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымтада бирелгән Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибен расларга.

2. Түбәндәге боерыкларны үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитетының «Тарифлар билгеләү турындагы эшләрне карау тәртибен раслау хакында» 2009 елның 21 апрелендәге 57а номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитетының 2009 елның 21 апрелендәге 57а номерлы боерыгы белән расланган Тарифлар билгеләү турындагы эшләрне карау тәртибенең аерым бүлекчәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында» 2013 елның 11 июнендәге 160 номерлы боерыгын.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П.Борисовага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 4 мартындагы 32 номерлы боерыгы белән расланды

**Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) билгеләү тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1. Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар (бәяләр, өстәмәләр, өстәлмәләр, ставкалар) (алга таба – тарифлар) билгеләүнең әлеге тәртибе тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының гамәл кылу вакытын һәм тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

тарифларны формалаштыру – гариза, кирәкле документлар һәм нигезләү материаллары әзерләү һәм тапшыру (алга таба – гариза һәм документлар), шулай ук тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимнәрне карау процедурасы;

гариза – сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар билгеләү (алга таба – тарифлар билгеләү) турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) мөрәҗәгать итү;

чыгымнар – җайга салына торган товарларны җитештерү, эшләр, хезмәтләр күрсәтү барышында кулланыла торган табигать ресурслары, чимал, материаллар, ягулык, энергия, төп фондлар, хезмәт ресурслары бәясе һәм аңа кагылышлы башка чыгымнар;

база чоры – җайга салу чорына (исәп-хисап елына) кадәрге календарь елы;

җайга салынулы чор – тарифлар билгеләнә торган чор (ел).

Гариза бирүчеләр:

җайга салынулы оешмалар (Татарстан Республикасы торак фондын техник инвентаризацияләүгә ставкалар, кадастр эшләренә максималь дәрәҗәдә чик бәяләр билгеләнгәндә);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләнгәндә);

җирле үзидарә органнары, җәмәгать туклануы предприятиеләре (гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган продукциягә (товарларга) бәяләр билгеләнгәндә);

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, «Урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре, «Урманчылык» дәүләт казна учреждениеләре (халыкка сатыла торган каты ягулыкка (күмер, утын) ваклап сату

бәяләре, гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу килешүе буенча түләү ставкалары билгеләнгәндә).

3. Тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу, әгәр эшчәнлек өлкәләренең берсе җайга салынулы булса, товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) һәм аларны җитештерүгә тотылган чыгымнарны аерым исәпкә алып баруга нигезләнә.

4. Дәүләт тарафыннан җайга салу, оешу-хокук формаларына, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, барлык җайга салынулы оешмаларга да кагыла.

5. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне карау өчен кабул итү Дәүләт комитетына гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар белән мөрәҗәгать иткән гариза бирүче инициативасы белән гамәлгә ашырыла.

Документлар (яки аларның күчермәләре) гариза бирүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм гариза бирүченең мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар тарифларны билгеләү сәбәпләрен күрсәтергә, аларны расларга һәм тарифларны билгеләү дәлилләрен нигезләргә тиеш.

Коммерция һәм хезмәт серен үз эченә алган документлар закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

6. Дәүләт комитеты үз вәкаләтләре кысаларында сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтүгә, эшләргә, товарларга тарифлар билгеләүне мөстәкыйль рәвештә башлап җибәрергә мөмкин.

7. Тарифларны җайга салганда тарифлар билгеләүнең түбәндәге ысуллары кулланыла:

икътисадый нигезләнгән чыгымнар (сарыфлар) алымы;

тарифларны индексацияләү алымы.

8. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

тарифлар билгеләү турында карар кабул итү;

тарифлар билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү.

9. Тарифлар билгеләү турындагы карар проекты Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар һәм федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары вәкилләре катнашында Килештерү комиссиясе утырышында карала.

10. Тарифлар билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында кабул ителә.

## 2. Тарифларны билгеләү тәртибе һәм үзенчәлекләре

11. Гариза бирүче, әлеге Тәртипнең 1 һәм 2 кушымталарына ярашлы рәвештә документлар теркәп, Дәүләт комитетына гариза җибәрә.

12. Дәүләт комитеты гариза кергән көннән алып 14 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында санап үтелгән барлык документларның булу-булмавын, аларның законнар һәм әлеге Тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә.

13. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимнәрне карау (тапшырылган документларны тикшерү, анализлау), тарифларны исәпләп чыгару Дәүләт

комитеты хезмәткәрләре исәбендәге экспертлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14. Эксперт гаризаны һәм документларны карап тикшерү нәтиҗәләре, тарифлар билгеләү турында эксперт бәяләмәсе әзерләү, закон нигезендә тарифлар билгеләү турында Дәүләт комитеты карары проектын әзерләү өчен җаваплы.

15. Тарифлар билгеләү өчен барлык документлар булып, алар закон таләпләренә җавап биргән очракта, гариза бирүченең тәкъдиме карап тикшерүгә кабул ителә.

16. Документларның булмау факты билгеләнгәндә яки тапшырылган документлар тарифларны җайга салу, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәгәндә, Дәүләт комитеты тикшерү тәмамланганнан соң 5 эш көненнән соңга калмыйча, гариза бирүчедән (почта, электрон почта яки телефон аша) документлар соратып ала.

Гариза бирүче 14 эш көне эчендә җайга салу органы сораткан документларны тапшыра.

Соратыла торган документлар гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән срокта тапшырылмаса яки анализ һәм исәп-хисап ясау өчен җитәрлек булмаган күләмдә тапшырылганда, Дәүләт комитеты сорала торган документларны тапшыру срогы тәмамланган вакыттан башлап кимендә 5 эш көне эчендә, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гариза бирүчегә (почта, электрон почта аша) тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне караудан баш тарту турында хәбәр итә.

17. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне караудан баш тарту әлеге Тәртиптә каралган тәртиптә баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң Дәүләт комитетына кабат мөрәҗәгать итү өчен каршылык була алмый.

18. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим кабул ителгән көннән башлап тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне карау срогы 90 эш көне тәшкил итә.

19. Тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча эксперт тарифлар билгеләү турында бәяләмә әзерли, шулай ук тарифлар билгеләү турында Дәүләт комитеты карары проектын әзерли, аңа сәнәгать булмаган өлкә тарифларын җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге (алга таба – бүлек) башлыгы, юридик бүлек башлыгы һәм бүлекне җитәкли торган рәис урынбасары кул куя.

Дәүләт комитетының 2020 елның 4 мартындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгать булмаган һәм социаль өлкәләрдә тарифлар билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты
Рәисенә

__________________________ тарифлар билгеләү турында

**ГАРИЗА**

Гариза бирүче:____________________________________________________________

(гариза бирүченең тулы атамасы)

Гариза бирүченең реквизитлары:______________________________________________

(ОГРН, ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

Гариза бирүченең юридик адресы:_____________________________________________

Гариза бирүченең почта адресы: _____________________________________________

Гариза бирүченең җитәкчесе:_________________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме, элемтә өчен телефон, электрон почта адресы)

Гариза бирүченең тарифлар билгеләү өчен мөрәҗәгать итү нигезе: _____________

_______________________________________________________________________

_

Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән таләп (тарифлар дәрәҗәсе):

_______________________________________________________________________

Җайга салу чоры ______________________________________________________

Кушымта: Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына тапшырылган документлар һәм материаллар реестры (битләрен нумерацияләп).

Гариза бирүченең җитәкчесе ___________________ ___________________

(имза) (тулы имза)

Дата «___» _____________ 20___ ел

Мөһер урыны

Дәүләт комитетының 2020 елның
4 мартындагы 32 номерлы
боерыгы белән расланган
Сәнәгать булмаган һәм социаль
өлкәләрдә тарифлар билгеләү
тәртибенә 2 нче кушымта

**Тарифлар билгеләү өчен тапшырыла торган**
**ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

1. Җайга салынулы оешма җитәкчесе кул куйган тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим.
2. Тарифлар билгеләү (үзгәртү) кирәклеген нигезли торган кыскача аңлатма язуы.
3. Гамәлгә кую документларының күчермәләре.
4. Җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешманың исәпкә алу сәясәте турындагы боерык һәм счетларның эш планы күчермәсе.
5. Эшчәнлек төрләре буенча чыгымнарны бүлү ысулы.
6. Алдагы чор өчен һәм соңгы хисаплылык датасына бухгалтерлык хисаплылыгы (предприятие балансы, Ф-2 «Керемнәр һәм сарыфлар турында»).
7. Тарифларны икътисадый нигезләү өчен сәбәпче булган документларның күчермәләре.
8. Үзкыйммәт калькуляциясе өчен матди, арадаш эшчәнлек чыгымнарын, башка чыгымнарны һәм башка статьяларны аңлату.
9. Хезмәткә түләү фонды исәпләмәсе.
10. Җайга салынулы оешмада гамәлдә булган норматив һәм тармак актлары (тариф килешүе, хезмәт өчен түләү турында нигезләмә, премияләү турында нигезләмә, күмәк килешү, штат расписаниесе, П-4 «Хезмәткәрләр саны, хезмәт хакы һәм хезмәткәрләр хәрәкәте турында мәгълүматлар» һ.б.).
11. Җайга салынулы оешма һәм эшчеләр һәм хезмәткәрләр категорияләре буенча тулаем алганда айлык хезмәт хакы турында белешмә.
12. База чорында төп финанс-икътисад күрсәткечләре турында белешмә.
13. Кирәкле табышны нигезләү.
14. База чорында табыш бүлү турында белешмә.
15. Дәүләт комитеты сайтында Документлар/ БДАМС/ БДАМС үрнәкләре/ Региональ үрнәкләр/ Кулланучылар базары* адресы буенча урнаштырылган PRIL.TV.TOP.2.16(v2.0) региональ үрнәге.

* Гариза бирүчеләргә – гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган продукциягә (товарларга) өстәмә бәяләр билгеләү өчен.